| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2022 г. Заинск № 645

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында белем бирү системасын мониторинглауны гамәлгә ашыру турында» 2014 елның 18 апрелендәге 850 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 05 августындагы 662 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 мартындагы 450 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында белем бирү системасын мониторинглауны гамәлгә ашыру турында» 2014 елның 18 апрелендәге 850 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Мониторинг узарга тиешле мәгариф системасы турында мәҗбүри мәгълүмат исемлеге 2 кушымтасының 5 бүлеге 10 пунктына түбәндәге эчтәлекле «д» - «ж» пунктчаларын өстәргә:

«д) төп гомуми белем бирү программалары буенча аккредитация күрсәткечләрен үтәү - башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча;

е) урта һөнәри белем бирүнең төп белем бирү программалары буенча аккредитация күрсәткечләрен үтәү;

ж) югары белемнең төп белем бирү программалары буенча аккредитация күрсәткечләрен үтәү.».

1.2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәгариф системасын мониторинглауны гамәлгә ашыру кагыйдәләре 1 кушымтасының 3 пунктында

“мәгарифне үстерү” сүзләреннән соң “белем бирүнең сыйфаты,” сүзләрен өстәргә.

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42